КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 31 октябрь г.Казань № 970

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 ел, 5 август, 555 нче карары белән расланган Дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 ел, 5 август, 555 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 24 июль, 586 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «бәяләр (тарифлар)» сүзләреннән соң «(алга таба – мәҗбүри таләпләр)» сүзләрен өстәргә;

5 пунктта «бәяләр (тарифлар)» сүзләреннән соң «(алга таба – тикшерү субъектлары)»;

6 пунктның икенче абзацында «табигый монополияләр субъектлары эшчәнлеге» сүзләреннән соң «транспорт чараларын техник карау үткәргән өчен түләүнең чик күләмнәре»;

түбәндәге эчтәлекле 6.1 – 6.7 пунктлар өстәргә:

«6.1. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) шул исәптән куркынычка йөз тоткан якын килүне кулланып гамәлгә ашырыла.

Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда куркынычка йөз тоткан якын килүне куллану максатларында контроль субъектлары эшчәнлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) аерым

төрләрен оештырганда куркынычка йөз тоткан якын килүне куллану һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 ел, 17 август, 806 нчы карары белән расланган Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген һәм (яки) алар файдалана торган җитештерү объектларын куркынычның билгеле бер категориясенә яки куркынычның билгеле бер классына (категориясенә) кертү кагыйдәләре һәм әлеге Тәртип нигезендә куркынычның билгеле бер категориясенә кертелергә тиеш.

Контроль субъектлары эшчәнлеген куркынычның билгеле бер категориясенә кертү Дәүләт комитеты тарафыннан әлеге Тәртипнең 6.2 пунктында күрсәтелгән куркынычның билгеле бер категориясенә контроль субъектлары эшчәнлеген кертү критериясе нигезендә гамәлгә ашырыла, әгәр мондый критерийләр федераль законнарда яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнмәсә.

6.2. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда контроль субъектлары эшчәнлеген куркынычның билгеле бер категориясенә кертү түбәндәге критерийлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

а) урта куркыныч категориясенә:

тикшерүләр планы проектын формалаштырган көннән өч ел эчендә мәҗбүри таләпләрне бозу факты булганда электр энергетикасы, җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү, су агызу, каты көнкүреш калдыклары белән эш итү буенча хезмәт күрсәтүләр, даими монополияләр өлкәләрендә контроль субъектлары эшчәнлеге;

эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашырганда, тикшерүләр планы проектын формалаштырган көннән дүрт ел эчендә мәҗбүри таләпләрне бозу факты булганда гражданнарга товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатуны гамәлгә ашыручы контроль субъектлары эшчәнлеге;

тикшерүләр планы проектын формалаштырган көннән дүрт ел эчендә мәҗбүри таләпләрне бозу факты булганда тарифлар билгеләнгән көннән соң ике ел эчендә аларны яңадан карау (тәгаенләү) турында гариза белән мөрәҗәгать итмәгән контроль субъектлары эшчәнлеге;

б) уртача куркыныч категориясенә:

тикшерүләр планы проектын формалаштырган көннән өч ел эчендә мәҗбүри таләпләрне бозу факты булмаганда электр энергетикасы, җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү, су агызу, каты көнкүреш калдыклары белән эш итү буенча хезмәт күрсәтүләр, даими монополияләр өлкәләрендә контроль субъектлары эшчәнлеге;

эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашырганда, тикшерүләр планы проектын формалаштырган көннән дүрт ел эчендә мәҗбүри таләпләрне бозу факты булмаганда гражданнарга товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатуны гамәлгә ашыручы контроль субъектлары эшчәнлеге;

тикшерүләр планы проектын формалаштырган көннән дүрт ел эчендә мәҗбүри таләпләрне бозу факты булмаганда тарифлар билгеләнгән көннән соң ике ел эчендә аларны яңадан карау (тәгаенләү) турында гариза белән мөрәҗәгать итмәгән контроль субъектлары эшчәнлеге;

в) түбән куркыныч категориясенә – контроль субъектларының уртача һәм урта куркыныч категорияләренә кертелмәгән бүтән эшчәнлеге.

Тикшерүләр планы проектын формалаштырган көннән дүрт ел эчендә мәҗбүри таләпләрне бозу факты булганда түбән куркыныч категориясенә кертелгән контроль субъекты эшчәнлеге уртача куркыныч категориясенә кертелергә тиеш.

6.3. Әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра торган эшчәнлекләренә бирелгән куркыныч категориясенә бәйле юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне планлы тикшерүләр түбәндәге вакыттан вакытка кабатлана:

урта куркыныч категориясе өчен – өч елга бер тапкырдан еш түгел (электр энергетикасы, җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү, су агызу, каты көнкүреш калдыклары белән эш итү буенча хезмәт күрсәтүләр, даими монополияләр өлкәләрендә җайга салына торган эшчәнлекне гамәлгә ашыраучы контроль субъектлары өчен – елга бер тапкырдан еш түгел);

уртача куркыныч категориясе өчен – дүрт елга бер тапкырдан еш түгел (электр энергетикасы, җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү, су агызу, каты көнкүреш калдыклары белән эш итү буенча хезмәт күрсәтүләр, даими монополияләр өлкәләрендә җайга салына торган эшчәнлекне гамәлгә ашыраучы контроль субъектлары өчен – ике елга бер тапкырдан еш түгел).

түбән куркыныч категориясенә кертелгән контроль субъектларына мөнәсәбәттә планлы тикшерүләр үткәрелми.

6.4. Дәүләт комитеты планлы тикшерүләр үткәргән юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр исемлеген алып бара.

Эшчәнлекләре куркыныч категориясенә кертелгән контроль субъектларын планлы тикшерүләр үткәрелә торган юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр исемлекләренә кертү Рәиснең (Рәис урынбасарының) юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген куркынычның тиешле категориясенә кертү турында карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

6.5. Контроль субъектлары эшчәнлеген куркыныч категорияләренең берсенә кертү турында карарны яңадан карау очрагында куркыныч категориясен үзгәртү турында карар Рәис (Рәис урынбасары) тарафыннан кабул ителә.

Контроль субъектлары эшчәнлеген куркыныч категорияләренең берсенә кертү турында карарда булмаганда контроль субъекты эшчәнлеге түбән куркыныч категориясенә кертелгән дип санала.

6.6. Эшчәнлеге куркыныч категорияләренең берсенә кертелгән контроль субъекты соравы буенча Дәүләт комитеты билгеләнгән тәртиптә контроль субъектына аның эшчәнлеген куркыныч категориясенә кертү турында мәгълүматны, шулай ук контроль субъекты эшчәнлеген куркынычның билгеле бер категориясенә керткәндә файдаланылган белешмәләрне бирә.

6.7 Эшчәнлекләре куркыныч категориясенең берсенә кертелгән контроль субъектлары Дәүләт комитетына билгеләнгән тәртиптә аларга элек бирелгән куркыныч категориясен үзгәртү турында гариза бирергә хокуклы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин